Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Советы Карары

22 октябрь 2017 ел № 62

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталык һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләрне билгеләү максатларында, , Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен» 1 нче номерлы кушымта нигезендә расларга
2.2012 елның 11 маендагы 36 номерлы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл башлыгы Х.Х.Гәрәев